# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
# «ШИЛЬНӘБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
# МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАР

«27 » февраля 2020 ел № 41/4

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Шильнәбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2005 елның 30 декабрендәге «Тукай муниципаль районы Шильнәбаш авыл җирлеге Советы депутаты статусы турында нигезләмәне раслау хакында» 17 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә Тукай муниципаль районы Шильнәбаш авыл җирлеге Советы

## КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Шильнәбаш авыл җирлеге Советының «Тукай муниципаль районы Шильнәбаш авыл җирлеге Советы депутаты статусы турында нигезләмәне раслау хакында» 2005 елның 30 декабрендәге 17 номерлы карары белән расланган Депутатлар статусы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертергә:

2. Әлеге Нигезләмәнең 17 статьясы 4 өлеше 2 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

2) эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шәхсән яки ышанычлы затлар аша шөгыльләнергә;

2.1) түбәндәге очраклардан тыш, коммерцияле яки коммерциясез оешма белән идарә итүдә катнашырга:

а) сәяси партия, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органы белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтенең съездында (конференциядә) яки гомуми җыелышында катнашу;

б) Россия Федерациясе субъекты законында билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе субъектының югары вазыйфаи затына (Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесенә) алдан хәбәр итеп, коммерциясез оешма белән идарә итүдә (сәяси партия, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органы белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашудан, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтенең съездында (конференциядә) яки гомуми җыелышында катнашудан тыш) түләүсез нигездә катнашу;

в) Россия Федерациясе субъектының муниципаль берәмлекләре советында, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә тәкъдим итү;

г) гамәлгә куючысы (акционеры, анда катнашучысы) муниципаль берәмлек булган оешманың идарә органнарында һәм ревизия комиссиясендә муниципаль берәмлек исеменнән оешманы гамәлгә куючы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен яисә муниципаль милектә булган акцияләр (устав капиталында өлешләр) белән идарә итү тәртибен билгеләүче муниципаль хокукый актлар нигезендә түләүсез нигездә муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен тәкъдим итү;

д) федераль законнарда каралган башка очраклар;

3. Әлеге карарны Шильнәбаш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет Рәисе                                        О.А. Гончарова